СОВЕТ ГОРОДА ЗАИНСКА
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Орджоникидзе, д. 49, г.Заинск, 423522

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЗӘЙ ШӘҺӘР СОВЕТЫ
Орджоникидзе ур.,49 йорт, Зәй шәһәре,423522

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

03.03.2021 г. Заинск № 33

**«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Зәй шәһәре муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» 2013 елның 29 октябрендәге 129 номерлы Зәй муниципаль районының Зәй шәһәре Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 декабрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Зәй шәһәрендә җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектын карау буенча гавами тыңлаулар беркетмәсе һәм гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә нигезендә, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 33 статьясына, Зәй шәһәре Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Зәй шәһәре Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Зәй шәһәре муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» 2013 елның 29 октябрендәге 129 номерлы Зәй муниципаль районының Зәй шәһәре Советы карарына 16:48:060209:2077 16:48:060209:2090 кадастр номерлы җир кишәрлекләрендә урнашкан ОД-3 зонасын (мәгариф объектлары зонасы) һәм Ж-3 зонасын (күпфатирлы объектлар төзелеше зонасы) ОД-1 зонасына (күпфункцияле иҗтимагый-эшлекле төзелеш зонасы) үзгәртү өлешендә (1-кушымта) үзгәреш кертергә.
2. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Зәй шәһәре Советының оештыру бүлегенә әлеге карарны Зәй муниципаль районының http://zainsk.tatarstan.ru рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны җир мәсьәләләре, экология һәм торак-коммуналь хуҗалык буенча депутат комиссиясенә (Р.В.Әгъләмов) йөкләргә.

**Совет Рәисе** **Р.Г. Кәримов**